КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 ноябрь г.Казань № 983

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карары белән расланган Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карары белән расланган Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта:

«б» пунктчада «медицина оешмаларын» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы медицина оешмаларын «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы

5 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәдә каралган өлкәннәргә күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме күрсәтү бүлеген җиһазландыру стандарты нигезендә автомобильләр белән һәм балаларга күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме күрсәтү бүлеген җиһазландыру стандарты нигезендә җиңел автомобиль машиналары белән тәэмин итү.»;

7 нче пунктның икенче һәм өченче абзацларында «дару препаратлары һәм медицина әйберләре сатып алуга» сүзләрен «дару препаратлары, медицина эшләнмәләре һәм автомобильләр сатып алуга» сүзләренә алыштырырга.

2. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин